**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в состав Комиссии по предупреждению и ликвидации чрезвычайных ситуаций и обеспечению пожарной безопасности Республики Татарстан**

В связи с переходом отдельных лиц на другую работу **постановляю:**

1. Внести в состав Комиссии по предупреждению и ликвидации чрезвычайных ситуаций и обеспечению пожарной безопасности Республики Татарстан (далее – Комиссия), утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 8 сентября 2007 года № УП-511 «О мерах по организации и координации государственного управления в области защиты населения и территорий от чрезвычайных ситуаций и пожарной безопасности в Республике Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 17 апреля 2009 года № УП-204, от 5 сентября 2009 года № УП-482, от 22 апреля 2011 года № УП-235, от 11 июня 2012 года № УП-457, от 7 марта 2013 года № УП-208, от 6 августа 2013 года № УП-716, от 9 октября 2013 года № УП-1007, от 22 февраля 2014 года № УП-198, от 19 марта 2015 года № УП-298, от 14 ноября 2015 года № УП-1094, от 3 февраля 2016 года № УП-76, от 12 декабря 2016 года № УП-1092, от 16 июня 2017 года № УП-507, от 19 апреля 2018 года № УП-325, от 19 марта 2019 года № УП-174, от 11 апреля 2019 года № УП-216, от 10 сентября 2019 года № УП-531 и от 10 февраля 2020 года № УП-73), следующие изменения:

а) вывести из состава Комиссии Ф.С. Абдулганиева, Д.Р. Динниулова, Б.Г. Петрова, А.С. Пуряева, Л.Р. Сафина, Н.Н. Хабипова, Ф.Ю. Хайрутдинова, Д.Г. Хамитова, А.В. Хохорина;

б) ввести в состав Комиссии:

Айзатуллина Марата Мансуровича – министра строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан;

Волынец Ирину Владимировну – Уполномоченного по правам ребенка в Республике Татарстан (по согласованию);

Гайнутдинову Лилию Ахатовну – заместителя руководителя Волжско-Камского межрегионального управления Федеральной службы по надзору в сфере природопользования (по согласованию);

Ильина Федора Степановича – исполняющего обязанности директора филиала федерального бюджетного учреждения «Всероссийский научно-

исследовательский институт лесоводства и механизации лесного хозяйства» «Восточно-Европейская лесная опытная станция» (по согласованию);

Мубаракшина Азата Фаридовича – руководителя Приволжского управления Федеральной службы по экологическому, технологическому и атомному надзору (по согласованию);

Мухаметзянова Фяргата Усмановича – заместителя начальника полиции (по охране общественного порядка) Министерства внутренних дел по Республике Татарстан (по согласованию);

Шагиахметова Мидхата Рафкатовича – заместителя Премьер-министра Республики Татарстан – министра экономики Республики Татарстан;

Хвостикова Игоря Владимировича – начальника Управления Федеральной службы безопасности Российской Федерации по Республике Татарстан (по согласованию);

в) изложить в следующей редакции наименования должностей членов Комиссии:

Л.Р. Габдурахманова – «начальник Управления Государственной инспекции безопасности дорожного движения Министерства внутренних дел по Республике Татарстан (по согласованию)»;

И.М. Гарипова – «первый заместитель Руководителя Аппарата Президента Республики Татарстан – начальник Управления по работе с территориями Президента Республики Татарстан»;

Т.В. Каримуллина – «исполняющий обязанности министра по делам гражданской обороны и чрезвычайным ситуациям Республики Татарстан»;

Ф.М. Ханифова – «министр транспорта и дорожного хозяйства Республики Татарстан».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
26 августа 2021 года
№ УП-675

**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт идарәсен оештыру һәм координацияләү чаралары турында» 2007 елның 8 сентябрендәге ПУ-511 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-204 номерлы, 2009 елның 5 сентябрендәге ПУ-482 номерлы, 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-235 номерлы, 2012 елның 11 июлендәге ПУ-457 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы, 2013 елның 6 августындагы ПУ-716 номерлы, 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы, 2014 елның 22 февралендәге ПУ-198 номерлы, 2015 елның 19 мартындагы ПУ-298 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1094 номерлы, 2016 елның 3 февралендәге ПУ-76 номерлы, 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1092 номерлы, 2017 елның 16 июнендәге ПУ-507 номерлы, 2018 елның 19 апрелендәге ПУ-325 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2019 елның 11 апрелендәге ПУ-216 номерлы, 2019 елның 10 сентябрендәге ПУ-531 номерлы һәм 2020 елның 10 февралендәге ПУ-73 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Ф.С. Габделганиевны, Д.Р. Динниуловны, Б.Г. Петровны, А.С. Пуряевны, Л.Р. Сафинны, Н.Н. Хәбиповны, Ф.Й. Хәйретдиновны, Д.Г. Хәмитовны, А.В. Хохоринны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Айзатуллин Марат Мансур улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын;

Волынец Ирина Владимировнаны – Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне (килешү буенча);

Гайнетдинова Лилия Әхәт кызын – Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Ильин Федор Степановичны – «Бөтенроссия урманчылык һәм урман хуҗалыгын механикалаштыру фәнни-тикшеренү институты» федераль бюджет учреждениесе филиалы «Көнчыгыш Европа урман-тәҗрибә станциясе» директоры вазыйфаларын башкаручыны (килешү буенча);

Мөбарәкшин Азат Фәрит улын – Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе җитәкчесен (килешү буенча);

Мөхәммәтҗанов Фәргать Усман улын – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы полиция башлыгы урынбасарын (җәмәгать тәртибен саклау буенча) (килешү буенча);

Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улын – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министрын;

Хвостиков Игорь Владимировичны – Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Л.Р. Габдерахмановның – «Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе башлыгы (килешү буенча)»;

И.М. Гариповның – «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы»;

Т.В. Кәримуллинның – «Татарстан Республикасы граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры вазыйфаларын башкаручы»;

Ф.М. Хәнифовның – «Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миннеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 26 август
№ ПУ-675